**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**31 октябрь 2025 ел** **№ 13**

**«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты совхозы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 13 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

2. 2025 елның 14 ноябренә 08 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

3. 2025 елның 14 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

4. 2025 елның 14 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан (курсантлардан), I төркем инвалидларыннан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

- урамнарны яктыртуны ясау;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бируне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

-янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тротуарларны төзү, ремонтлау;

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүме?

«РИЗА» «КАРШЫ»»?

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Нырты авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов

ТР Кукмара муниципаль районы Нырты авыл башкарма комитеты
Ныртинский сельский исполнительный комитет Кукморского муниципального района РТ
ОГРН 1061675011243
ИНН 1623008592